**СОВЕТ БОЛЬШЕКАБАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

ул.Южная, дом 1, село. Малые Кабаны
422623, Телефон/факс(84378)4-22-02
E-mail: Bkab.La@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ КАБАН ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

Коньяк урамы,1 нче йорт,
Кече Кабан авылы,
422623 Телефон/факс(84378)4-22-02
E-mail: Bkab.La@tatar.ru

**2025 елның 27 ноябре** **23 номер**

# КАРАР

**Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Лаеш муниципаль районының Олы Кабан авыл җирлегенең Олы Кабан торак пунктында(Ягодная ур., Спас-Преображенский ур., Төньяк ур. территориясендә) гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 маддәсе, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Лаеш муниципаль районының Олы Кабан авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Лаеш муниципаль районының Олы Кабан авыл җирлеге башлыгы КАРАР ИТТЕ:

1.2025 елның 8 декабрендә 18 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы, Лаеш районы, Олы Кабан авыл җирлегенең Олы Кабан торак пунктында(Ягодная ур., Спас-Преображенский ур., Төньяк ур. территориясендә) үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

2.Лаеш муниципаль районы Олы Кабан авыл җирлеге Олы Кабан торак пункты территориясендә(Ягодная ур., Спас-Преображенский ур., Төньяк ур. территориясендә) яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, көндезге бүлектә укучы студентлардан һәм балачактан инвалидлардан тыш, 2025 елда үзара салымны 5000 сум күләмендә кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

- тротуарларны төзү, ремонтлау (Спас-Преображенский урамыннан Овражная урамына кадәр – чокыр аша; Аэропорт-Казан трассасыннан зират ягына беренче керү юлына кадәр);

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан

Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) һәм Олы Кабан авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында рәсми кабул ителгән көннән алып биш көн эчендә игълан итәргә.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Башлык урынбасары - Татарстан Республикасы
Лаеш муниципаль районы Олы Кабан
авыл җирлеге Советы рәисе А.И. Маков